**ГЛАВА ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: 8 (84378) 2-51-51
факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: 8 (84378) 2-51-51
факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

2024 елның «29» гыйнвары 5-ПГ номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгының «Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән граждан белән эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү төзү турында эш бирүче тарафыннан, муниципаль хезмәткәрнең соңгы хезмәт урыны буенча яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 июлендәге 48-ПГ номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«"Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен контрольдә тотуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2018 елның 03 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ««««Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турында электрон рәвештә белешмәләр формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 10 июлендәге 1017 номерлы карары белән, КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгының «Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән граждан белән эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү төзү турында эш бирүче тарафыннан, муниципаль хезмәткәрнең соңгы хезмәт урыны буенча яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 июлендәге 48-ПГ номерлы карарына (алга таба - муниципаль район башлыгының 2015 елның 20 июлендәге 48-ПГ номерлы карары) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 1 пунктның «б» пунктчасында «муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия» сүзләрен «хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Муниципаль район Башлыгының 2015 елның 20 июлендәге 48-ПГ номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 5 пунктта «оешма мөһере» сүзләреннән соң «яисә кадрлар хезмәте мөһере (мөһерләр булганда)» сүзләрен өстәргә;

2) 7 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) граждан муниципаль хезмәттән чыгар алдыннан биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 661 маддәсендә каралган хезмәт кенәгәсендә һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар буенча, муниципаль хезмәт үткән чорда;»

3) 10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 20 маендагы 26-РС номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе, граждан-хокукый шартнамә шартларында хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфасын биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә) ризалык бирү турында, әгәр әлеге оешманың дәүләт, муниципаль (административ) идарәсенең аерым функцияләре аның вазифа (хезмәт) бурычларына керсә, гражданның язма мөрәҗәгатен карарга, шулай ук кабул ителгән карар турында гражданга хәбәр итәргә тиеш.».

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р. Т. Гарифуллинга йөкләнә.

**Муниципаль район Башлыгы** **И.Ф.Зарипов**